ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.03.2021 с.Старое Дрожжаное № 114

Торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү һәм исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау һәм эшләү Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 июнендәге 274 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктындагы икенче баганада 5 пунктчаны төшереп калдырырга;

2.6 пунктның икенче баганасында:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;»;

түбәндәге эчтәлекле 4-8 пунктчалар өстәргә:

«4) 14 яшькә җитмәгән мөрәҗәгать итүче гаиләсенең барлык әгъзалары өчен бала туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

5) Мөрәҗәгать бирүче һәм/яки аның гаилә әгъзалары өчен никах төзү турында таныклык-гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

6) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

7) Никахны өзү турында таныклык - гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

8) Опека билгеләү турында белешмәләр - Россия Федерациясе Пенсия фондына.»;

3.4.1 пунктта:

«Йорт китабыннан өземтәләр (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта)» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәү турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5-9 пунктчалар өстәргә:

«5) бала туу турында таныклык;

6) никахлашу турында таныклык;

7) ата булуны билгеләү турында таныклык;

8) никахны өзү турында таныклык;

9) опека билгеләү турында белешмәләр.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Д.А. Сатдинов